**РЕСПУБЛИКА ТАТАРСТАН**

**РУКОВОДИТЕЛЬ**
**Исполнительного комитета муниципального образования «поселок городского типа Актюбинский» Азнакаевского муниципального района**

ул. Губкина, д.24, п.г.т. Актюбинский,
Азнакаевский муниципальный район,
423304
тел.: (8-85592) 3-16-63, 6-12-21
факс: (8-85592) 3-16-63
E-mail: Svetlana.Strukova@tatar.ru

**ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ**

**Азнакай муниципаль районы Актүбә бистэсе башкарма комитеты ҖИТӘКЧЕСЕ**

Губкина урамы, 24, п.г.т. Актюбинский,
Азнакай муниципаль районы, 423304
тел.: (8-85592) 3-16-63, 6-12-21
факс: (8-85592) 3-16-63
E-mail: Svetlana.Strukova@tatar.ru

---

**ПОСТАНОВЛЕНИЕ** **КАРАР**

«20» декабрь 2018 ел № 51

Татарстан Республикасы Азнакай муниципаль районының Актүбә шәһәр тибындагы поселогы Советы карары белән расланган Татарстан Республикасы Азнакай муниципаль районының «Актүбә шәһәр тибындагы поселогы» муниципаль берәмлегенең җирдән файдалану һәм төзелеш кагыйдәләренә үзгәрешләр кертү турында проектны әзерләү хакында (24.08.2015 №22, 30.09.2016 №15, 05.09.2017 №16, 02.07.2018 №30 карарлар редакциясендә)

Россия Федерациясе Шәһәр төзелеше кодексының 8, 33 статьялары һәм «Россия Федерациясендә җирле үзидарәне оештыруның гомуми принциплары турында» 2003 елның 06 октябрендәге 131-ФЗ номерлы Федераль закон нигезендә, 2018 елның 20 декабрендәге «Актүбә шәһәр тибындагы поселогы» муниципаль берәмлегенең җирдән файдалану һәм төзелешләр кагыйдәләре проектын әзерләү комиссиясе бәяләмәсе нигезендә карар бирәм:

1. Татарстан Республикасы Азнакай муниципаль районының Актүбә шәһәр тибындагы поселогы Советының 30.12.2013 №38 карары белән расланган Татарстан Республикасы Азнакай муниципаль районының «Актүбә шәһәр тибындагы поселогы» муниципаль берәмлегенең җирдән файдалану һәм төзелеш кагыйдәләренә үзгәрешләр кертү турында проектны әзерләүгә керешергә (24.08.2015 №22, 30.09.2016 №15, 05.09.2017 №16, 02.07.2018 №30 карарлар редакциясендә)

1.1. Россия Федерациясе Шәһәр төзелеше кодексына кертелгән үзгәрешләргә туры китерергә.

2. Татарстан Республикасы Азнакай муниципаль районының «Актүбә шәһәр тибындагы поселогы» муниципаль берәмлегенең җирдән файдалану һәм төзелеш кагыйдәләренә үзгәрешләр кертү турында проектны әзерләү тәртибен һәм срокларын билгеләргә (1 нче кушымта).

3. Әлеге карарны Татарстан Республикасы хокукый мәгълүматының рәсми порталында түбәндәге веб-адрес буенча бастырып чыгарырга: http://pravo.tatarstan.ru

һәм Азнакай муниципаль районының рәсми сайтында Интернет "мәгълүмат-коммуникацион челтәрендә түбәндәге веб-адрес буенча» урнаштырырга: http://aznakaevo.tatar.ru.

4. Әлеге карарның үтәлешен тикшереп торуны үземдә калдырам.

Җитәкче И.И. Мөхәммәтҗанов

Татарстан Республикасы Азнакай муниципаль районының «Актүбә шәһәр тибындагы поселогы» муниципаль берәмлеге Башкарма комитеты җитәкчесе 2018 елның «20» декабрендәге 51 карарына 1 нче кушымта

**Татарстан Республикасы Азнакай муниципаль районы «Актүбә шәһәр тибындагы поселогы» җирдән файдалану һәм муниципаль берәмлек төзелеше кагыйдәләренә үзгәрешләр кертү турында проектны әзерләү эшләрен башкару тәртибе һәм сроклары**

| N | Татарстан Республикасы Азнакай муниципаль районының «Актүбә шәһәр тибындагы поселогы» муниципаль берәмлегенең җирдән файдалану һәм төзелеш кагыйдәләренә үзгәрешләр кертү турында проектны әзерләү эшләрен уздыру тәртибе | Эшләр уздыру срогы |
|---|---|---|
| 1. | Җирдән файдалану һәм төзелеш кагыйдәләренә үзгәрешләр кертү турында проектны әзерләү эшләрен оештыру. | 2018 елның IV кварталы |
| 2.<br><br>2.1. | Җирдән файдалану һәм төзелеш кагыйдәләренә үзгәрешләр кертү турында проектны әзерләү һәм килештерү.<br>Җирдән файдалану һәм төзелеш кагыйдәләренең 1 нче, 25-30 статьяларын Россия Федерациясе Шәһәр төзелеше кодексына кертелгән үзгәрешләргә туры китерү.<br>Җирле үзидарә органы тарафыннан территорияне планлаштыру документларын әзерләү турындагы бүлекне әзерләү.<br>Җирдән файдалану һәм төзелеш кагыйдәләренә үзгәрешләр кертү турында проектны килештерүдә катнашучы хезмәтләр һәм ведомстволар искәрмәләренә комментарийлар әзерләү. | 2018 елның IV кварталы |
| 3.<br><br><br>3.1. | Җирдән файдалану һәм төзелеш кагыйдәләренә үзгәрешләр кертү турында фикер алышу.<br>Гавами тыңлаулар үткәрү.<br>Азнакай муниципаль районының «Актүбә шәһәр тибындагы поселогы» муниципаль берәмлеге башлыгының Азнакай муниципаль районының «Актүбә шәһәр тибындагы поселогы» муниципаль берәмлегенең җирдән файдалану һәм төзелеш кагыйдәләренә үзгәрешләр кертү турында карар кабул итү өчен юлламасы (гавами тыңлаулар беркетмәсе һәм гавами тыңлаулар нәтиҗәләре турында бәяләмә) Татарстан Республикасы Азнакай муниципаль районының Актүбә шәһәр тибындагы поселогы Советына кабат тәкъдим итү датасын күрсәтеп, аны эшләп бетерү өчен раслау яисә җибәрү турында карар кабул итү өчен үзгәрешләр кертү хакында карар кабул итү өчен юлламасы. | 2019 елның I кварталы |